Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авыл Советы

КАРАРЫ

№ 91 16 декабрь 2019 года

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының 2018 елның 27 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл башкарма комитеты нигезләмәсе турында» гы 78 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Ямаш авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының 2018 елның 27 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл башкарма комитеты нигезләмәсе турында»гы 78 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекне тешереп калдырырга;

1.2. 4 бүлектә:

1.2.1. 4.1 пунктының 4 пунктчасының еченче абзацында «торак биналарны үзгәртеп планлаштыру» сүзләрен «күпфатирлы йорттагы биналарны үзгәртеп планлаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.2. 4.1 пунктының 4 пунктчасының бишенче абзацын тешереп калдырырга;

1.2.3. 4.1 пунктының 6 пунктчасының уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнаша;»;

1.2.4. 2 пунктны 4.2 пункты дип санарга;

1.2.5. 4.2 пунктының унөченче абзацында «күзәтүчесез хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чаралар» сүзләрен "хуҗасы булмаган хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлек" сүзләренә алмаштырырга;

1.2.6. түбәндәге эчтәлектәге унбишенче, уналтынчы абзацлары естәргә:

«-1992 елның 7 февралендәге «-кулланучылар хокукларын яклау турында» 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра»;

«-Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә, узирекле корылманы сүтү, үзирекле корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карарлар кабул итә.».

1.2.7. 3 пунктны 4.3 пункты дип санарга;

1.2.8. түбәндәге эчтәлектәге 4.4 - 4.7 пунктлары естәргә:

«4.4. Җирлекнең башкарма комитеты җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәүне федераль законнар,

җирлек Советы карарлары, җирлек башлыгы карарлары һәм күрсәтмәләре нигезендә тәэмин итә.

4.5. Җирлекнең башкарма комитеты җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

4.6. Җирлекнең башкарма комитеты, әгәр бу федераль законнарда каралган булса, башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга, шулай ук башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертелмәгән, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән үз компетенцияләреннән тешереп калдырылмаган башка мәсьәләләрне, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан һәм түләүләрнең естәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән тыш, җирле бюджетлар керемнәре исәбенә хәл итәргә хокуклы.

4.7. Җирлекнең башкарма комитеты үз вәкаләтләренең бер елешен гамәлгә ашыруны Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Әлмәт муниципаль районы бюджетына Җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешү тезергә хокуклы.».

2. Әлеге карарны торак пункты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: карарны Ямаш авылы, Совет урамы, 109а йорты; Зәй-Чишмә авылы, Верхняя урамы, 186 нчы йорт; Березовка авылы, Үзәк урам, 10 нчы йорт; «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Ямаш авыл
җирлеге башлыгы А.И. Чуркин